**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧЫБЫКЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**№122** **26.10.2018 ел**

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»**
**2014 елның 14 ноябрендәге**
**156 номерлы Зәй муниципаль районы**
**Чыбыклы авыл җирлеге Советы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлеше 32 бүлеге нигезендә, шулай ук «Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Чыбыклы авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 156 номерлы Зәй муниципаль районы Чыбыклы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

   1.1. 2 пунктта:

   а) 2 пунктчада «фатирларның өлешләре» сүзләрен өстәргә;

   б) 3 пунктчада «торак йортларның өлешләре» сүзләрен өстәргә;

   1.2. 3 пунктчада «бер торак бина (торак йорт)» сүзләрен «бер торак йорт» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер ай узгач кына.
3. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе** **И.Н.Гадершин**